| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Мунайкинского сельского поселения<br>Менделеевского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Монай авыл жирлеге Советы |

КАРАР

04.10.2023 ел №109

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлегендә
бюджет процессы турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советының 2022 елның 1 апрельындагы 61 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 41 статьясындагы 11 пункты үз көчен югалткан дип таныргa.

1.2. Нигезләмәнең 61 статьясында 2 пунктының 6 абзацы үз көчен югалткан дип таныргa.

1.3. Нигезләмәнең 21 статьясында 12 пунктының 3 абзацына түбәндәге редакциядә 4 һәм 5 пунктчалар өстәргә:

«4) хисап финанс елында файдаланылмаган товарларны җитештерүгә (реализацияләүгә) , эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән субсидияләрнең калган өлешләрен алучы агымдагы финанс елында субсидияләр (субсидия алучыларның күрсәтелгән субсидияләр финанс тәэминаты чыганагы булган акчаларын түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелгән субсидияләрдән тыш) алган очраклар һәм аларны кире кайтару тәртибе;

5) субсидияләр алучыларга һәм әлеге статьяның 5 пунктында күрсәтелгән затларга карата субсидияләр бирүче бюджет акчаларының Баш идарәчесе (идарәчесе) тарафыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәүләрен, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә тикшерүләрне гамәлгә ашыру турында нигезләмәләр .»

2. Әлеге карарны Монай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleeevsk.tatar.ru "Монай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Монай авыл җирлеге Советы рәисе Р.М.Кириллов